КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 май г.Казань № 378

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрү чыгымнарының бер өлешен түләү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 28 май, 435 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрү чыгымнарының бер өлешен түләү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 28 май, 435 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен татар текстында яңа редакциядә бәян итәргә: «Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрү чыгымнарының бер

өлешен түләү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан, шул исәптән Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»;

1 пунктны татар текстында яңа редакциядә бәян итәргә: «Бу карарга теркәлгән Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрү чыгымнарының бер өлешен түләү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан, шул исәптән Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.».

әлеге карар белән расланган Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрү чыгымнарының бер өлешен түләү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә:

исемен татар текстында яңа редакциядә бәян итәргә: «Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрү чыгымнарының бер өлешен түләү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан, шул исәптән Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе»;

1 пунктны татар текстында яңа редакциядә бәян итәргә: «Бу Тәртип Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрү чыгымнарының бер өлешен түләү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан, шул исәптән Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.».

2 пунктны татар текстында яңа редакциядә бәян итәргә: «Башка бюджетара трансфертлар коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрү чыгымнарының бер өлешен түләү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү максатларында, шул исәптән Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән Татарстан Республикасының муниципаль районнары (алга таба – муниципаль берәмлекләр) бюджетларына бирелә.»

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Һәр муниципаль берәмлек өчен башка бюджетара трансфертлар күләме коммуналь инфраструктура системасын модернизацияләү проектын гамәлгә ашыру өчен Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды – дәүләт корпорациясе акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтү турындагы шартнамә белән билгеләнә.»;

7 пунктның өченче абзацында «һәм Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтендә теркәлгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлек бюджетына муниципаль берәмлекнең финанс органы өчен Федераль казначылык Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган бердәм счетка күчерелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин